**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-44, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ 11.02.2025 ПР-27 № ______

Актаныш муниципаль районы территориясендә 2025 елгы язгы ташу куркынычы чорында язгы ташу суларының тискәре йогынтысын һәм аның нәтиҗәләрен булдырмау чаралары турында

2025 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм Актаныш муниципаль районы территориясен гадәттән тыш хәлләрдән кисәтү һәм яклау максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен яклау чаралары турында» 2025 елның 31 гыйнварындагы 47 номерлы карарлары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елгы язгы ташу чорында Актаныш муниципаль районы халкын һәм территориясен яклау буенча чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

2. Актаныш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы комиссиясе каршындагы Актаныш муниципаль районының 2025 елгы язгы ташу суларын үткәрүне контрольдә тоту һәм координацияләү буенча су ташуга каршы комиссия һәм эшче төркеме составын расларга. (2 нче кушымта).

3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә һәм авыл җирлекләре башлыкларына:

- язгы ташу чорында халыкны һәм Актаныш муниципаль районы территориясен яклау буенча чаралар планын үтәүгә, язгы ташуга әзерлек һәм аны үткәрү планын эшләргә;
- халыкка язгы ташу чорында ярдәм күрсәтү өчен, үз җирлекләрендә су ташуга каршы комиссияләр булдырырга, кизү торуны оештырырга, килеп туган вәзгыять турында районның язгы ташуга каршы тору комиссиясенә хәбәр итәргә (тел.3-44-22, 3-12-30);
- - су басуга әзерлек чараларын эшләргә һәм аларның үтәлешен даими тикшереп торырга, биналарны һәм корылмаларны, складларны һәм башка биналарны су басуны, матди кыйммәтләрне бозуны, шулай ук гидротехник корылмаларны, автомобиль юлларын һәм күперләрне җимерүне кисәтә торган кичектергесез чаралар уздыруга аерым игътибар бирергә;
- күздә тотылган барлык матди кыйммәтләрне су басу зоналарыннан вакытында чыгаруны тәэмин итәргә, шулай ук язгы ташу вакытында кичектергесез чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле матди ресурслар запасларын әзерләргә;

- объектлар, биналар һәм корылмалар, су үткәрү торбалары һәм күперләр, хуҗалык эчендәге автомобиль юлларында кар һәм боздан чистарту эшләрен оештырырга;
- су чыганакларының һәм сулыкларның пычрануын кисәтү максатларында су җыю корылмалары территорияләрен, минераль ашламалар саклау урыннарын санитар чистартуны оештырырга;
- су агызу чараларын, мотопомпаларны һәм су баскан биналардан су суыртып алган вакытта куллану өчен һәм кар сулары җыелган урыннардан файдалану өчен башка чараларны югары әзерлеккә китерергә;
- язгы ташу суларының югары дәрәҗәсе күтелә торган зоналарга даими контроль урнаштырырга;
- үз территорияләрендәге гидротехник корылмаларны шәхси контрольгә алырга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итәргә.

4. «Яран» ТМШ директоры, «Коммунсервис» МУП, «Актаныш юллары» ҖЧҖ, «ИТК» ҖЧҖ күпкатлы торак йортлардан эрегән кар һәм яңгыр суларын агызу эшләрен оештырырга һәм ведомство карамагындагы территориядән кар чыгару эшләрен оештырырга.

5. «Таттелеком» ААҖ Яр Чаллы ЗЭЭЧ Актаныш РЭЭЧ баш инженерына барлык торак пунктларны телефон элемтәсе белән тәэмин итәргә. Авария бригадаларын һәм мөмкин булган гадәттән тыш хәл нәтиҗәләрен бетерү өчен булган техниканы югары әзерлектә тотарга.

6. «Татавтодор» АҖ Минзәлә филиалы «Актаныш» юл ремонт-төзелеш идарәсе башлыгы, «Актаныш юллары» ҖЧҖ, «ИТК» ҖЧҖ барлык суүткәргеч торбаларны, күперләрне һәм юлларны кардан чистартуны оештырырга, мөмкин булган гадәттән тыш хәлдә эшләү өчен кирәкле техниканы һәм формированиеләрнең шәхси составын даими әзерлектә тотарга, ком, вак таш, ягулык-майлау материаллары һәм авария-торгызу эшләрен башкару өчен башка материаллар запасы булдырырга.

7. Актаныш районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә йөкләргә:
- терлекләрне, орлык фондын, фуражны, минераль ашламалар, техника һәм башка җиһазларны саклау буенча чаралар күрергә;
- су басмый торган урыннарда 1-1,5 айга исәпләнгән азык, фураж,салам запасы булдырырга;
- терлекчелек һәм склад биналарының түбәләрен һәм стеналарын, шулай ук хуҗалык территориясендә урнашкан су үткәрү торбаларын һәм күперләрне кардан чистартуны оештырырга;
- авария-торгызу эшләрен башкару өчен төзелеш материаллары, ягулык-майлау материаллары резервын булдырырга.

8. Түбән Кама электр челтәре "Актаныш РЭЧ" башлыгына:
- су басу мөмкин булган зоналарга эләгә торган электр белән тәэмин итү линияләрен, трансформатор подстанцияләренә тикшерү үткәрергә;
- куркынычсыз эксплуатацияләү буенча чаралар күрергә, авария хәлендәге бригадаларның һәм техниканың составын югары әзерлектә тотарга.

9. «Коммунсервис» МУП директорына Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзорның Чаллы территориаль бүлеге идарәсе башлыгы урынбасары белән берлектә:
- СанПиН нигезендә җитештерү контроле кысаларында суның сыйфатын даими тикшереп торуны тәэмин итәргә;

- эчәргә яраклы суның сыйфатын лаборатория тикшеренүләре өлешендә эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан җитештерү контролен үткәрүне контрольдә тотарга.

10. "Актаныш РҮХ" ДАССО баш табибына:

- гадәттән тыш хәлдә халыкка беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәрләр исемлеген билгеләргә;
- язгы ташу суларының югары дәрәҗәдә булуы көтелә торган зоналар янында медикаментлар запасы булдырырга.

11. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгына:

- язгы ташуга каршы чаралар үткәргәндә, халыкка куркыныч янау турында хәбәр итү, районда тәртип саклау буенча төрле яклап ярдәм күрсәтү өчен оператив төркемнәр төзү;
- су басу куркынычы белән бәйле рәвештә кешеләрне вакытлыча эвакуацияләү мөмкин булган торак пунктларда гражданнарның мөлкәтен саклау чараларын һәм матди кыйммәтләрне саклау объектларын билгеләргә.

12. "Актаныш РЭГС " башлыгына:

- газ торбаүткәргечләренең су киртәләре һәм чокырлар аша чыгуын тикшерергә;
- кирәкле авария материаллары запасын булдырырга.

13. «Үзәк регион су хуҗалыгы» эксплуатациясе участогы башлыгына:

- насос станцияләренең тәүлек буе эшләвен тәэмин итү;
- мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен кирәкле матди ресурслар резервын булдыру.

14. Авыл җирлекләре башлыкларына, оешма, учреждение җитәкчеләренә, милек формалрына бәйсез рәвештә, буалар һәм плотиналар булган урыннарда, эшче төркем белән бергәләп, кышкы чорның начар нәтиҗәләрен бетереп, язгы ташу суларын үткәрү өчен сулыкларны алдан әзерләргә.

15. Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгына:

- зыян күргән халыкка ярдәм күрсәтү өчен кирәкле азык-төлек, он, кием-салым һәм урын кирәк-яраклары запасын алдан күрергә;
- күчмә туклану һәм халыкны җылыту пунктларын оештырырга.

16. "Актаныш РДВБ" ДБУ башлыгына район территориясендәге үләт базларының торышын даими тикшереп торырга, үләт базларын су басуны булдырмау максатыннан чаралар үткәрергә.

17. “Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе” МКУ башлыгына, мәктәп директорларына балаларның тормыш иминлеген тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрергә, язгы ташу вакытында ялгыз, өлкән яшьтәге пенсионерларны һәм инвалидларны карарга ярдәм итәргә.

18. Районның барлык язгы ташуга каршы комиссияләренә, 21.03.2025 елдан башлап, көн саен (иртән һәм кич) Сөн һәм Биҗады елгалары яр буе полосасы буйлап су күтәрелү торышы турында мәгълүматны 3-12-30 телефоны буенча яисә электрон адресы буенча aktanyshedds01@mail.ru тапшырырга.

19. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

20. Актаныш муниципаль районының «2024 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм Актаныш муниципаль районы территориясен яклау чаралары турында» 01.02.2024нче елның ПР-21 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

21. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Бариев

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
______ №____ карарына
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә 2025 елның язгы ташу куркынычы чорында язгы ташу суларының тискәре йогынтысын һәм аның нәтиҗәләрен булдырмау чаралары планы

| № т/б | Чара атамасы | Башкаручылар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **Оештыру чаралары** | | | |
| 1 | «Татарстан Республикасы РСЧС (Россия гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм системасы) ТП (территориаль ярдәмче системасы) Актаныш звеносын 2025 елгы язгы ташуның тискәре нәтиҗәләрен киметүгә әзерләү чаралары турында» Актаныш муниципаль районы КЧС (гадәттән тыш хәлләр комиссиясе) һәм ОПБ (янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү) утырышын үткәрү.<br>Алдагы еллардагы язгы ташу нәтиҗәләрен исәпкә алып, язгы ташуга каршы үткәрелгән чараларны бәяләү. | Актаныш муниципаль районы гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС ) һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) | 20.03.2025 кадәр |
| 2 | Язгы ташу нәтиҗәләрен киметү һәм бетерү өчен ашыгыч чаралар күрүне таләп итә торган мәсьәләләрне даими карау | районның гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС ) һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) эшче төркеме | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 3 | “Россия ГТХМ ТР буенча Баш идарәсе дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәте 15 янгын-коткару отряды" 103 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге (ПСЧ) хезмәткәрләренең су басу ихтималы булган зонага эләгүче район торак пунктларына су басуга каршы чаралар әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү максатларында чыгуларын оештыру | “Россия ГТХМ ТР буенча Баш идарәсе дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәте 15 янгын-коткару отряды" 103 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге, районның гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС ) һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) эшче | 20.03.2025 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | төркеме (килешү буенча) | |
| 4 | Районның су объектларында су дәрәҗәсен, гидротехник корылмаларның торышын тикшереп тору өчен вакытлыча күзәтү челтәре (гидрологик постлар) оештыру. Язгы ташу торышы үсешенә бәйле фаразлау һәм мониторинглау гидрометеорологик мәгълүматны вакытында һәм тулыландырып тапшыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү | Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнары (алга таба ОМСУ) (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 5 | Язгы ташу торышы үсешенә бәйле фаразлау һәм мониторинглау гидрометеорологик мәгълүматны вакытында һәм тулыландырып тапшыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), “Россия ГТХМ ТР буенча Баш идарәсе дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәте 15 янгын-коткару отряды"  103 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге(килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 6 | Су басу ихтималы булган зоналардан халыкны, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм матди кыйммәтләрне өлешчә эвакуацияләү (күчерү) планнарын төгәлләштерү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 20.03.2025 кадәр |
| 7 | Язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне саклау буенча оператив төркемнәрдә гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС) һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) гамәлләре буенча күнегүләр үткәрү. | Актаныш муниципаль районы гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС ) һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) рәисе | 20.03.2025 кадәр |
| 8 | Район халкына гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС ) һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) турында хәбәр итү системаларының эшчәнлеген тикшерү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 15.03.2025 кадәр |
| 9 | Су басу зонасына эләгүче торак пунктлар белән радиоэлемтә оештыру. Элемтә көчләрен һәм чараларын исәпләп чыгару | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 15.03.2025 кадәр |
| 10 | Халыкны үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү чыганакларын су басуны булдырмауга юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү.<br>Су басканда, су басу, аларны юдыру һәм йогышсызландыру буенча норматив документлар нигезендә чаралар күрергә | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 11 | Йорт биләмәләре территорияләрен, шул исәптән санитар узелларны, ишегалды бәдрәфләрен су басу очракларында, йорт биләмәләре янындагы территорияләрдә дезинфекция чаралары үткәрү буенча чаралар күрергә.<br>Дезинфекция чаралары үткәрүгә махсуслаштырылган оешмалар белән | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу үткәннән соң |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | килешүләр төзергә (алдан) | | |
| 12 | Торак пунктлар территорияләрен су баскан очракта, халыкның вакытлыча булу пунктларын нормаль тормыш эшчәнлеге өчен кирәкле барлык әйберләр белән җиһазландырып (тәэмин итеп) әзерләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу вакытына |
| 13 | Язгы ташу вакытында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерү. Халык өчен язгы ташу чаралары буенча белешмәлекләр эшләү. | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 14 | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2025 елда су басу куркынычы булган чорда хәвеф-хәтәрне йомшарту һәм гадәттән тыш хәлләргә җавап бирү планына төзәтмәләр кертү. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары ( килешү буенча) | 15.02.2025 кадәр |
| 15 | 2025 елның язгы ташу чорында Татарстан Республикасы халкын һәм территорияләрен яклау чараларына җәлеп ителә торган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары һәм оешмалар арасында мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыру турындагы килешүләргә төзәтмәләр кертү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.03.2025 кадәр |
| 16 | Актаныш муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте (ЕДДС) бердәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасының тиешле муниципаль звенолары составына керүче оешмалар, ведомстволарның диспетчерлык хезмәтләре белән күнегүләр үткәрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | аерым план буенча |
| 17 | Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы органнары һәм көчләре белән язгы ташу куркынычы чорында региональ һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча комплекслы өйрәнүләрдә катнашу | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары ( килешү буенча) | 31.03.2025 кадәр |
| 18 | Язгы ташу, табигый янгыннар белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, урман янгыннарыннан икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын яклау мәсьәләләрен хәл итү, шулай ук урман янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләр һәм чаралар белән төбәкара маневр ясау мәсьәләләрен хәл итү буенча уртак комплекслы өйрәнүләрдә катнашу | Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы ГТХМ, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле узидарә органнары (килешү буенча), Актаныш муниципаль районының РСЧС ТП | II квартал 2025 ел |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| **Гамәли чаралар** | | | |
| 1 | Гидротехник корылмаларны (буаларны, плотиналарны, дамбаларны) кар суларының максималь күләмен үткәрүгә әзерләү эшләрен оештыру, шулай ук су чыгарудагы задвижкаларны ачу һәм көйләү белән сусаклагычларның (буаларның) минималь кышкы (куркынычсыз) дәрәҗәсенә кадәр саклап калу юлы белән гидротехник корылмаларның гидравлик эш режимын саклау | Милекчеләр җирле үзидарә һәм гидротехник корылмалардан файдаланучы оешмалар (килешү буенча) | 10.03.2025 кадәр |
| 2 | Боз өемнәренең килеп чыгуын кисәтү, боз ваклауны оештыру, гидротехник корылмаларның бөтен фронты буенча су агызу тишекләре аша боз кисәкчекләрен үткәрү | Милекчеләр җирле үзидарә һәм гидротехник корылмалардан файдаланучы оешмалар (килешү буенча) | язгы ташу чорында |
| 3 | Инженерлык саклау корылмалары өстеннән күзәтчелекне көчәйтү, көчле су басулар фаразланган очракта тәүлек буе кизү торуны һәм ышанычлы хәбәр итү һәм элемтә системасын оештыру | Милекчеләр җирле үзидарә һәм гидротехник корылмалардан файдаланучы оешмалар (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 4 | Актаныш муниципаль районы су объектларының су басу куркынычы булган участокларында боз кисү эшләрен башкаруны оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | март 2025 ел |
| 5 | Су басуга дучар булган торак пунктлар янында авиация техникасын куллану юлы белән халыкка ярдәм күрсәтү өчен вакытлыча вертолет мәйданчыклары (мөмкинлекләре булганда) әзерләү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.03.2025 кадәр |
| 6 | Актаныш муниципаль районының бердәм дәүләт гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы составына керүче оешмалар, ведомстволарның диспетчерлык хезмәтләре, җаваплы вазыйфаи затлар мәгълүматлары белән актуальләштерелгән телефон белешмәләре белән тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.03.2025 кадәр |
| 7 | Кышкы чорның уңайсыз нәтиҗәләрен вакытында ачыклау һәм бетерү максатларында мелиоратив системаларын һәм корылмаларын кабат тикшерү | Милекчеләр җирле үзидарә һәм гидротехник корылмалардан файдаланучы оешмалар (килешү буенча) | 25.03.2025 кадәр |
| 8 | Халык һәм территория өчен куркыныч тудыручы, имин эксплуатацияләү тәэмин ителми торган гидротехник корылмаларына комиссия тикшерүе уздыру.<br>Гидротехник корылмаларны тикшерү актларын төзү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге идарәсенең Чаллы территориаль бүлегенә (килешү буенча) | 30.04.2025 кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 9 | Ветеринария-санитария таләпләренә туры китереп, язгы ташу сулары белән су басу зонасына керүче авыл хуҗалыгы объектларын һәм үләт базларын тикшерү. Үләт базларын су басуны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештыру | Район дәүләт ветеринария берләшмәсе, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.04.2025 кадәр |
| 10 | Су объектларының су саклау зоналарын пычратуга һәм язгы ташу суларының сыйфатын начарайтуга юл куймау буенча оештыру һәм инженер-техник чаралар үткәрү,бигрәк тә сыек калдыклар тупланган районнарда, чистарту корылмаларында һәм агу химикатларын саклау урыннарында, елга һәм сулыкларның боз катламнарына, ведомство причалларына автотранспорт керү, елга транспортын төяү һәм бушату урыннарында | җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (вәкаләтләр кысаларында), "Средволгаводхоз" филиалы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | Оештыру чаралары - 15.03.2025 кадәр практик яктан-язгы ташу чорында |
| 11 | Максималь күләмдә кар суларын үткәрү өчен район юлларында су үткәрү торбаларын, яңгыр канализацияләрен, каналларны, яңгыр сулары канализациясе корылмаларын чистарту буенча чаралар үткәрүне оештыру | “А-Строй” ҖЧҖ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 12 | Су басу ихтималы булган зонага эләгүче электр челтәре комплексы объектларын (электр тапшыру линияләрен, подстанцияләрне, трансформатор подстанцияләрен), газ бүлү челтәрләрен тикшерү. Аларны имин эксплуатацияләү буенча чаралар күрү. | «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы Түбән Кама электр челтәрләре, Актаныш РЭЧ, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ, җирле үзидарә органнары(килешү буенча) | 25.03.2025 елга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 13 | Күперләрне тикшерү һәм ныгыту, аларны торгызу өчен материаллар һәм чаралар әзерләү. Потенциаль куркыныч түбән су асты ясалма корылмаларына махсус контроль билгеләү. Вакытлы кичүләр һәм кичү төзү урыннарын билгеләү | "Главтатдортранс" ДКУ, "Волго-Вятскуправтодор" ФКУ, җирле узидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 14 | Язгы ташу чорында автомобиль юлларының һәм ясалма корылмаларның әзерлеген һәм аларны карап тоту дәрәҗәсен тикшерүне оештыру | "Главтатдортранс" ДКУ, "Волго-Вятскуправтодор" ФКУ, җирле узидарә органнары(килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында<br>. |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 15 | Мөмкин булган су басу зоналарына керә торган торак биналардан һәм халыкның яшәешен тәэмин итү системалары объектларыннан кар суларын чыгару буенча эшләрне оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 25.03.2025 кадәр |
| 16 | Ашыгыч авария-торгызу эшләре башкарылган очракта инженерлык, юл-төзелеше һәм башка кирәкле техниканы әзерләү, аны тиешле күләмдә ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 20.03.2025 кадәр |
| 17 | Гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен түбәндәгеләрне булдыру:<br>финанс, матди-техник чаралар;<br>инерт һәм сорбцияләүче материаллар | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары ( килешү буенча) | 20.03.2025 кадәр |
| 18 | Ташу вакытында зыян күргән кешеләргә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру өчен әзерлек эшләре үткәрү. Медицина ресурслары резервын вакытлыча актырту | Актаныш ДАССУ РҮХ, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 01.04.2025 кадәр |
| 19 | Язгы ташу чорында зыян күргән халыкның беренчел яшәешен тәэмин итү өчен әзерлек эшләре үткәрү | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары ( килешү буенча) | 01.04.2025 кадәр |
| 20 | Суның сыйфаты начарланган очракта ашыгыч чаралар күрү өчен эчәргә яраклы сыйфатлы су әзерләү предприятиеләрендә зарарсызландыручы реагентларның өстәмә запасларын (бер айдан да ким булмаган эш өчен) булдыруны тәэмин итү. Су белән тәэмин итү чыганакларының сыйфатына һәм эчәргә яраклы суның сыйфатына җитештерү лабораториясе контролен көчәйтү, халыкка бирелә торган эчәргә яраклы суның сыйфаты, һәм якланганлыгына һәм су җыю корылмаларының санитар ышанычлылыгына бәя бирү | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының милекчеләре һәм баланс тотучылары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 21 | Торак пунктларны эчәр су белән тәэмин итү чыганакларын су баскан очракта эчәр су китерү өчен шартлар тудыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 22 | Халыкны үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү чыганакларын су басуны булдырмауга юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү. Су баскан очракта аларны юу һәм дезинфекцияләү буенча норматив документлар нигезендә чаралар күрү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 23 | Йорт биләмәләре территорияләрен, шул исәптән санитария узелларын, һәм ишегалды бәдрәфләрен су баскан очракта, йорт биләмәләре янындагы территорияләрдә дезинфекция чаралары үткәрү буенча чаралар күрү. Махсуслаштырылган оешмалар белән дезинфекция чараларын үткәрүгә шартнамәләр төзү | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | язгы ташу үткәннән соң |
| 24 | Халыкның тормышын беренче чиратта тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле мөлкәт белән вакытлыча урнаштыру пунктларының әзерлеген тикшерүне оештыру | җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 25.03.2025 кадәр |
| **Контроль чаралар** | | | |
| 1 | Торак-коммуналь, юл, энергетика, медицина предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренең язгы ташу чорына әзерлеге турындагы докладларын тыңлау | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ОПБ) һәм гадәттән тыш хәлләр комиссиясе (КЧС ) | 25.03.2025 кадәр |
| 2 | Халыкка су объектларының факттагы һәм көтелгән торышы, торак пунктларның һәм икътисад объектларының су басу ихтималы, халыкның куркынычсызлыгы янавы турында халыкка үз вакытында хәбәр итү | “Россия ГТХМ ТР буенча Баш идарәсе дәүләт янгынга каршы хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәте 15 янгын-коткару отряды" 103 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Актаныш мәгълүмат - редакция үзәге» | язгы ташуга кадәр һәм язгы ташу чорында |
| 3 | Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган эчә торган суның сыйфатына, ачык су чыганакларының, су алу җайланмаларының торышына санитар-эпидемиологик контрольне оештыру | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Яр Чаллы шәһәре территориаль бүлегенең Актаныш районындагы филиалы (килешү буенча), су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының милекчеләре һәм баланс тотучылары (килешү буенча) | 10.05.2025 кадәр |

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
______ №_____ карарына
2 нче кушымта

Актаныш муниципаль районының язгы ташуга каршы комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Бариев И.Ш. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы - комиссия рәисе; |
| Мортазин И.М. | РФ ГТХМ ТР буенча Баш идарәсенең 15 нче янгын сүндерү коткару отряды, 103 нче янгын сүндерү-коткару (ПСЧ) бүлеге башлыгы - комиссия рәисе урынбасары; |
| Демидов Р.Т. | Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары-комиссия рәисе урынбасары. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Минһаҗев М.Р. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы; |
| Закиров А.А. | - "Әлмәтгаз" эксплуатация-җитештерү идарәсе РЭГС башлыгы; |
| Абдрахманов Ф. А. | - "Актаныш РДВБ " ДБУ башлыгы; |
| Хузахметов И.Ш. | - "Яран" ТМШ директоры; |
| Шәрипов Р. Р. | - "Коммунсервис" МУП директоры вазифаларын башкаручы; |
| Хәев А. Р. | - "Актаныш район үзәк хастаханәсе" ДАССУ баш табибы; |
| Идрисов Р.И. | - «Татавтодор» АҖ Минзәлә филиалының Актаныш юл ремонтлау-төзелеш идарәсе башлыгы; |
| Гаязов Р. А. | - "Актаныш юллары" ҖЧҖ башлыгы; |
| Имамов З.А. | - «ИТК» ҖЧҖ; |
| Хәернасов Р.Ф. | - Район электр элемтәсе узелы баш инженеры; |
| Хафизова Л.М. | - ТР буенча кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (Яр ЧаллыТБ); |
| Рәхмәтуллин А.М. | - «Актаныш АТХ» ҖЧҖ директоры; |
| Шакиров М. М. | - Түбән Кама электр челтәре"Актаныш РЭЧ" башлыгы; |
| Шакирова Р. М. | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы; |
| Сәлимгәрәев Н.Ә. | - Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы; |
| Мулюкова Р.И. | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы; |
| Хәсәнов Р.А. | - ФГБВУ башлыгы; |
| | авыл җирлекләре башлыклары |

*Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган затлар килештерү буенча комиссия составына кертелә